МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.07.2023 № 351-осн

Казан шәһәре

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомство бүләкләре турында» 2019 елның 26 мартындагы 186-он номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомство бүләкләре турында» 2019 елның 26 мартындагы 186-он номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 20 сентябрендәге 495-осн номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы
министрлыгының 2023 елның
26 июлендәге 351-осн номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомство бүләкләре турында» 2019 елның 26 мартындагы 186-он номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы турындагы нигезләмәнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләре белән алыштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләре белән алыштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибенең 5 пунктының икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга.